РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ

БОЕРЫК

« 12 » декабрь 2022г. с. Тюлячи № 272

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 7 сентябрендәге 174 номерлы «Муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсе тарафыннан түләүле хезмәтләр һәм керем китерә торган башка эшчәнлек күрсәтү турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә,

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 7 сентябрендәге 174 номерлы «Муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсе тарафыннан түләүле хезмәтләр һәм керем китерә торган башка эшчәнлек күрсәтү турында» боерыгы (18.10.2022 № 235 боерык редакциясендә) белән расланган муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Җирлекара китапханәсендә 2022-2023 елга түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскурантына, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча чакырылган гражданнарның гаиләләреннән һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләреннән булган балалар» сүзләрен «махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге боерык 2022 елның 10 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев